КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 21 апрель г.Казань № 268

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 31 декабрь, 1101 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 31 декабрь, 1101 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 2 июль, 455 нче; 2016 ел, 3 октябрь, 701 нче; 2016 ел, 22 декабрь, 968 нче; 2017 ел, 13 ноябрь, 866 нчы; 2018 ел, 20 февраль, 102 нче; 2019 ел, 25 февраль, 125 нче; 2019 ел, 5 сентябрь, 775 нче; 2020 ел, 2 апрель, 250 нче, 2020 ел, 06 июль, 555 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«Гомуми нигезләмәләр» I бүлегенең утыз икенче абзацына «Камалыштта калган Севастопольдә яшәүче» билгесе белән бүләкләнгән затлар» сүзләрен өстәргә;

2.1.1 пунктның таблицасының 6 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «6. | Граждан белән бергә яшәү урыны буенча теркәлгән затлар турында белешмәләр*** | ****** | 30 көн»; |

таблицадан соң астөшермәләргә түбәндәге эчтәлекле «******» астөшермә өстәргә:

«******социаль хезмәтләр күрсәтү турында гариза биргәндә әлеге Тәртипнең 2.2 пунктындагы «а» - «е» пунктчаларында күрсәтелгән гражданнарның ташламалы категориясенә карамаган граждан тарафыннан мөстәкыйль рәвештә декларацияләнә.»;

3.1.1 пунктның таблицасының 9 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «9. | Граждан белән бергә яшәү урыны буенча теркәлгән затлар турында белешмәләр**** | ***** | 30 көн»; |

таблицадан соң астөшермәләргә түбәндәге эчтәлекле «*****» астөшермә өстәргә:

«*****социаль хезмәтләр күрсәтү турында гариза биргәндә әлеге Тәртипнең 3.2.4 пунктындагы «а» - «д» һәм «ж» пунктчаларында күрсәтелгән гражданнарның ташламалы категориясенә карамаган граждан тарафыннан мөстәкыйль рәвештә декларацияләнә.»;

6.1.1 пунктның таблицасының 6 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «6. | Граждан белән бергә яшәү урыны буенча теркәлгән затлар турында белешмәләр | *** | 30 көн»; |

таблицадан соң бирелгән астөшермәләргә түбәндәге эчтәлекле «***» астөшермәсен өстәргә:

«*** социаль хезмәтләр күрсәтү турында гариза биргәндә граждан тарафыннан мөстәкыйль рәвештә декларацияләнә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин